**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2024 елның "03"нче декабре 546№

2024 елның 19 июлендәге Әлки муниципаль
районы Башкарма комитетының
"Әлки муниципаль районы
Гражданнарны яклау идарәсе"
муниципаль казна учреждениесе
хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү шартлары турындагы нигезләмәне
раслау хакында" 348 нче номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында,2024 елның 12 сентябрендәге «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр булдырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасыныж 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 780нче номерлы Карары нигезендә, 2017нче елның 14нче августындагы «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 569нчы номерлы карары( 2017нче елның 28нче декабрендәге 1064нче номерлы,2020нче елның 16нчы октябрендәге 935нче номерлы,2020нче елның 4 нче апрелендәге 314нче номерлы,2022нче елның 19нчы августындагы 865нче номерлы,2022нче елның 15нче сентябрендәге 1007нче номерлы,2024нче елның 10нчы маендагы 315нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган карары нигезендә, Татарстан

Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 19 июлендәге Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының "Әлки муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе" муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 348нче номерлы карарына тубәндәге үзгәрешләр кертергә:
2. 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәреш кертергә:
   «Әлки муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе " муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында II Нигезләмәнең 2.1 пунктында 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

1нче таблица

| №. | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Хезмәт хакы күләме |
|---|---|---|
| 1. | Оешма башлыгы | 27 560 |
| 2. | Оешманың оператив дежур хезмәткәре | 21 200 |

2.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының http://alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Морадымов

Билалова А.А.
8(84346)21726